*Батыршина Г. Г. (РИИ, Казань)*

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ ЯССЫЛЫКТА ТЕЛНЕ ӨЙРӘНҮДӘ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

**Аннотация:** В статье рассматривается роль произведений устного народного творчества, а именно пословиц, в процессе обучения татарскому языку и формировании этнокультурной компетентности у студентов. Использование пословиц на занятиях, с одной стороны, имеет нравственно-воспитательный характер, с другой - позволяет усвоить лексико-семантические, грамматические и стилистические особенности татарского языка.

**Ключевые слова:** национальная культура, этнокультурная компетенция, устное народное творчество, лексико-семантические, грамматические и синтаксические особенности языка.

**The role of the works of folklore in language teaching in the national cultural plane**

**Abstract:** The article discusses the role of works of folklore, namely proverbs in teaching the Tatar language and the formation of ethnic cultural competence of students. The use of proverbs in class, on the one hand, has a moral and educational nature, on the other - makes it possible to learn lexical semantic, grammatical and stylistic features of the Tatar language.

**Key words:** national culture, ethnic cultural competence, folklore, lexical semantic, grammatical and syntactic features of the language.

Бүгенге җәмгыятьтә төрле өлкәдә югары компетентлы шәхесләр кирәклеге бәхәссез. Федераль белем бирү стандартлары да нәкъ менә шундый интеграль шәхесләр тәрбияләүне күздә тота. Димәк, белем бирү процессы компетентлы якын килү принцибына йөз тотып башкарылырга тиешлеге көн кебек ачык.

Россия ислам институтында татар теле дәресләре төп укыту программасы нигезендә алып барыла. Татар теленең грамматик төзелешен, аның кулланылыш үзенчәлекләрен аралашу процессында дөрес кулланырга өйрәтү, шулай ук сөйләү күнекмәләрен тагын да камилләштерү, ягъни туган телнең бар нечкәлекләрен тоеп, аңлап эш итү төп максатлардан санала. Татарстан Республикасында татар теленең дәүләт теле булуын, аның татар халкының рухи мирасын буыннан-буынга җиткерү, шулай ук милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салучы чара икәнлеген дә студентларга җиткерү төп бурыч булып тора. Шулай итеп, төп игътибар телне милли-мәдәни яссылыкта өйрәтү, икенче төрле әйтәндә, студентларда этномәдәни компетенцияләр булдыруга юнәлдерелә. Бу үз чиратында дәрестә, тел материалларыннан тыш, халыкның милли йолалары, гореф-гадәтләре, халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү аша алып барыла. Милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, язучы әсәрләре белән танышу, татар сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү дә зур әһәмияткә ия.

Халык иҗатының мөһим бер катламын тәшкил иткән мәкаль-әйтемнәр татар теле дәресләрендә аеруча киң кулланыла. Телебезнең җәүһәрләре саналган бу гыйбарәләргә тирән мәгънә, халык фәлсәфәсе, тормыш тәҗрибәсе, үткен фикер салынган. Алар «тормышта туктаусыз булып торган һәртөрле күренешләр, вакыйгалар, үзгәрешләрдә кешенең бәя бирергә теләве нигезендә туганнар һәм фольклорның халык арасында киң таралган, тел һәм сәнгати яктан бик нык эшләнгән, гаять тирән эчтәлеккә ия жанрларның берсе исәпләнәләр» [3, 6 б.], «сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирүче... халык хикмәте әсәрләре» [2, 12 б. ] булып торалар.

Татар теле дәресләрендә мәкальләрне өйрәнү һәм алардан файдалану, бер яктан, студентларда халыкның бай мирасына хөрмәт, тормышка аек караш, әдәплелек хисләре тәрбияләсә, икенчедән, халык авыз иҗатының бу төре телнең лексик-стилистик катламнарын билгеләргә, грамматик һәм синтаксик үзенчәлекләрен

ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, мәкальләрдә лексик берәмлекләрдән аеруча синоним һәм антонимнар еш кулланыла. Синонимнар төрдәш мәкальләр арасында күзәтелә: Ялгышлык кемдә булмый – Хаталык кемдә булмый; Гыйлем – акыл чырагы –Гыйлем – акылның нуры; Байлык – бер айлык, фәкыйрьлек – мәңгелек – Байлык бер айлык, ярлылык– тота белсәң, мәңгелек; Кәкрене бөкре күралмый һ.б. Антонимнар булган мәкальләр: Иске яңаны саклый; Яхшы тел яз кебек, яман тел көз кебек; Батыр даны ил телендә, куркак уе гел үлемдә; Күп сүзнең азы яхшы; Ялкау ашка килер, уңган эшкә килер һ.б.

Килеп чыгышы ягыннан яки кулланылыш активлыгына карап татар теленең сүзлек составын өйрәнгән вакытта шулай ук мәкальэйтемнәргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Лингвостатистик тикшеренүләр күрсәткәнчә, «Татар халык мәкальләре» җыентыгында (авторы – Н.Исәнбәт) 15268 мәкальдә гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр [7, 99 б.] һәм 1800 гә якын рус алынмалары [5, 52 б.] урын алган. Мисаллар: Наданның акылы үзендә; Сабыр иткән морадына җиткән; Мал мөлкәте тамактан керер, Җан мөлкәте колактан керер; Ат биядән туа, герой – анадан; Җил булмый, салам селкенми; Ел уйла, минутында эшлә; Шәп эфисәрнең начар солдаты булмый, шәп мөгаллимнең начар шәкерте булмый (надан, акыл, сабыр, морад, мал, мөлкәт, герой, салам, минут, эфисәр, солдат, начар, мөгаллим, шәкерт – алынма сүзләр) һ.б.

Мәкальләр һәр заман, һәр чор өчен хас. Аларның бер төркеме яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләрне чагылдырса, күпчелеге борынгы чорларда ук барлыкка килгән һәм үз составларында шактый гына искергән сүзләрне саклап килә. Шуңа күрә дәрестә телдәге архаизм һәм тарихи сүзләрне үзләштергәндә мәкаль-эйтемнәр файдалы чыганак булып тора. Мәсәлән: Җиметенә карама, егетенә кара (җимет – азык, җим, ашамлык); Исәпкә хисап, килегә кисап (киле – әйберләрне төеп ваклау өчен агач яки металлдан эшләнгән савыт); Һәрнәрсә чама белән, кымыз саба белән (саба – савыт мәгънәсендә); Үз эшем үземә җиткән, ычкырым теземә җиткән (ычкыр – ыштан бавы); Үзең койты булгач, көзгене хурлама (койты – ямьсез) һ.б. Әлбәттә, бу лексиканы үзләштергәндә, халкыбыз этнографиясенә караган материаллар белән танышу да күздә тотыла.

Телнең синтаксик үзенчәлекләрен өйрәнгән ва-

кытта, ягъни баш һәм иярчен кисәкләрне, җөмлә төрләрен һәм аларда сүзләр бәйләнешен ачыклаганда, мәкаль-әйтемнәргә мөрәҗәгать итү урынлы. Чөнки «мәкаль һәм әйтемнәр тәмамланган уйны белдерәләр, аерым сүз тезмәләренә таркалалар, синтаксик анализ вакытында баш һәм иярчен кисәкләргә ансат бүленәләр» [1, 56 б]. Г.Нәбиуллина фикеренчә, «... мәкальләр халыкның җанлы сөйләменә хас актив һәм продуктив синтаксик калыпларга нигезләнеп төзеләләр, ...гомумхалык телендә еш кулланылучы синтаксик төзелмәләрне чагылдыралар» [6, 174 б.] Паремияләр мисалында тезмә кушма җөмләләр һәм иярченле кушма җөмләләрне тикшерергә мөмкин: Җан чыгар, гадәт калыр; Дусның күңеле йомшак, теле каты; Идел даны белән боз китәр, атаң даны кыз китәр; Аз да җитә, күп тә бетә; Егет бул да җүләр бул, әмма ләкин җегәр бул; Я җаным бул, я җаным ал һ.б. (теркәгечсез һәм теркәгечле тезмә кушма җөмләләр); Сыйларга сыең булмаса, сыйпарга телең булсын; Яңгыр яуса, диңгезгә; Өең кысан булса да, күңелең иркен булсын; Атасы болан атмаганның, баласы колан атмас; Калган эшкә кар ява һ.б.(иярченле кушма җөмләләр).

Студентларның уйлау-фикерләү сәләтен тагын да яхшырту максатыннан түбәндәге күнегүне тәкъдим итәргә була: мәкаль-әйтемнәрнең беренче өлеше языла, икенче өлешен студентлар әйтергә тиеш яки киресенчә, икенче өлеше генә тәкъдим ителә. Мәсәлән: Ялгыз ял күрмәс, (күмәк ару белмәс); Картлар сүзен капчыкка сал, (яшьләр сүзен янчыкка сал); Туры әйткән котылган, (ялганлаган тотылган); (Сөйдергән дә тел), биздергән дә тел; (Кем эшләми), шул ашамый, (Егет кешегә) җитмеш төрле һөнәр дә аз һ.б.

Мәкальләрне студентларга иҗади эш итеп бирергә мөмкин. Төрле өлкәгә караган гыйбарәләрне нигез итеп алып, аларның мәгънәсен ачыклау, хикәя төзү, бердән, сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, тәрбия чарасы да булып тора. Мисалга Иргә итагать – фарыз; Алтын-көмешнең искесе булмас, ата-ананың бәһасе булмас; Хезмәт төбе – хәзинә; Хезмәтсез тапкан мал исәпсез китә;Изгелек җирдә ятмый; Сабыр төбе – сары алтын кебек гаилә, хезмәт, кешенең әхлакый сыйфатлары турындагы мәкальләрне алырга була.

Халкыбыз телендә мәкаль-әйтемнәр урынында йөрүче күп кенә канатлы тәгъбирләрнең башлангычы изге Коръән һәм

хәдисләргә барып тоташа [4, 45 б.]. Шуңа күрә аерым бер гыйбарәләрнең килеп чыгышын тикшерү, нигезен ачыклау максатында студентлар (бу очракта телне яхшы белүче шәкертләр җәлеп ителә) Коръән аятьләре, хәдисләр, төрле риватьләргә мөрәҗәгать итәргә, аның татар әдәбиятында чагылышын күрсәтергә, шул әчтәлектәге мәкальнең башка вариантларын эзләргә тиеш булалар. Мәсәлән, Кытайга барып булса да, гыйлем алыгыз гыйбарәсе, билгеле булганча, пәйгамбәребез Мөхәммәт с.г.в. нең халык арасында аеруча киң таралган хәдисенә нигезләнгән. Мисал итеп, Ай икегә ярылу; Атыңны элек абзарга яп, аннан Аллага таян; Изгелек ит тә суга сал һ. б. китерергә мөмкин. Болары инде тел җәһәтеннән генә түгел, бәлки халыкның рухи дөньясын тирәнрәк ачу, әхлакый-эстетик тәрбия бирү, мавыктыргыч һәм гыйбрәтле уку материалы булу ягыннан да файдалы чыганак була ала.

Шулай итеп, телне милли-мәдәни яссылыкта өйрәнүдә халык авыз иҗатының күркәм үрнәге булган мәкаль-әйтемнәрдән файдалану зур әһәмияткә ия булып тора. Халыкның бай тормыш тәҗрибәсен туплаган бу хикмәтле сүзләрне дәрестә куллану халык теле, тарихы, мирасына, сүз байлыгына, этник мәдәниятенә игътибар, хөрмәт белән карарга, җитди булырга өйрәтә. Туган телнең үзенчәлекләрен, бар нечкәлекләрен тоеп сөйләшергә, фикерне тулырак ачуда, сөйләмне баетуда әһәмиятле роль уйный.

Әдәбият:

1. Әхәтов Г. Татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 96 б.
2. Исәнбәт Н. С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. I том. – 2-нче басма. – Казан: Татар кит нәшр., 2010. – 618 б.
3. Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты // Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Татар., кит., нәшр., 1987. – Б. 5-36.
4. Мәхмүтов Х. Изге китаплар кайтавазы: аятьләр һәм хәдисләр җирлегендә туган тәгъбирләр. – Казан, 2012. – 224 б.
5. Мөгътәсимова Г. Татар халык мәкальләрендә рус алынмалары // Фәнни язмалар – 2001.– Казан: «Школа», 2002. – Б. 52-54.
6. Нәбиуллина Г.Ә. Татар халык мәкальләрендә кушма җөмлә синтаксисы. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – 208 б.

7. Федорова Э. Мәкаль сүз – акыл сүз, акыл сүз – мәгъкуль сүз // Милли мәдәният. – 2003. – №3. – Б. 99-101.

Чыганаклар:

1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. – 2010. – 618 б.; Т.2. – 2010. – 740 б.; Т.3. – 2010. – 799 б.

2. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов Г.Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә Туган тел. – Казан: «Мәгариф», 1998. – 176 б.